ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**16.06.2023**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1791**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021елның 16 августындагы 1930 номерлы карары белән расланган, муниципаль милектәге җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен һәм хосусый милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

2010 елның 27 июлендәге «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 210-ФЗ номерлы Федераль закон, 2022 елның 5 декабрендәге «Россия Федерациясе Җир кодексына һәм «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» Федераль законның 3.5 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 509-ФЗ номерлы Федераль закон,нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021елның 16 августындагы 1930 номерлы карары белән расланган, муниципаль милектәге җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен һәм хосусый милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (алга таба - административ регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә.

1.2. Административ регламентның 2.4.1 пунктындагы өченче абзацында «кырык биш көнгә кадәр» сүзләрен «утыз биш көнгә кадәр» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Зеленодольск муниципаль районы Советының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә Татарстан Республикасының (http://pravo.tatarstan.ru) хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы А.В. Старостин